ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№055 от «25» 06 2020 г.

«Татарстан Республикасы Мамадыш һәм Алабуга районнарының Мамадыш һәм Морт автоматлаштырылган газ бүлү станцияләре арасындагы югары басымлы газүткәргечне тоташтыру» линияле объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшәүчеләрнең«Татарстан Республикасы Мамадыш һәм Алабуга районнарының Мамадыш һәм Морт автоматлаштырылган газ бүлү станцияләре арасындагы югары басымлы газүткәргечне тоташтыру» линияле объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенчафикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41-43, 45, 46 статьялары, Мамадыш муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.«Татарстан Республикасы Мамадыш һәм Алабуга районнарының Мамадыш һәм Морт автоматлаштырылган газ бүлү станцияләре арасындагы югары басымлы газүткәргечне тоташтыру» линияле объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты – 2020 елның 26 июле,сәгать09:00 .

2.2. «Татарстан Республикасы Мамадыш һәм Алабуга районнарының Мамадыш һәм Морт автоматлаштырылган газ бүлү станцияләре арасындагы югары басымлы газүткәргечне тоташтыру» линияле объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты басылып чыккан көннән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр бер ай + бер көн;

2.3. Уздыру урыны - Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил ур., 23/33 йорт адресы буенча;

000064

2.4. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил ур., 23/33 йорт (эш көннәрендә-8.00 дән 17.00 гә кадәр);

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү срогы - 2020 елның 26 июленә кадәр (тел. 3-35-48).

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

3.1. 2020 елның 26 июненә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.2. «Татарстан Республикасы Мамадыш һәм Алабуга районнарының Мамадыш һәм Морт автоматлаштырылган газ бүлү станцияләре арасындагы югары басымлы газүткәргечне тоташтыру» линияле объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда әзерләргә һәм уздырырга.

4. 1 нче кушымта нигезендә оештыру комитеты төзергә (килешү буенча).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы

А.П. Иванов

Мамадыш
муниципаль районы
Башлыгының
25.06.2020,
№055 карарына
1 нче кушымта

Оештыру комитеты:

И.М. Дәрҗеманов - рәис, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе,
Р.Р. Хаҗиев - секретарь, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы.

Катнашты:
А.П. Куклев - Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе,
Р.М. Миннеханов - Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (районның баш архитекторы).